СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.11.2018 ел №4-38

2018 елның 18 ноябрендә җирле референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 апрелендәге № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча:
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-Катмыш һәм Еникей Чишмә авылларында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау;

-җирлек торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. Жирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү;

-Баскан һәм Катмыш торак пунктларында Җиңү һәм ял паркын төзекләндерү.

-Баскан авылында "Балтач чишмәсе" чишмәсен төзекләндерү

Баскан авылында тыл ветераннары хөрмәтенә һәйкәл кую

3. Жирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

-Катмыш, Баскан, Еникей Чишмә авылларында янгын гидрантлары урнаштыру

«ӘЙЕ» «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Катмыш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 905 номерлы карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Катмыш
авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе И.Г.Габидуллин